
Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль бюджет гомумбелем учреждениесе

«Югары Стәрле авылы төп гомуми белем бирү мәктәбе»

Сандугачлар белән иш булырлык-
Татарымның моңлы баласы мин.



# Нур Әхмәдиев

# Нәшер ителгән китаплары

“Аһәң ”,  1980;  “Баллы яңгыр”,1984; “Ак бишек ”, 1987 ; “Сөембикә йол-
дызлыгы”, 1988; “Кояш эзләүче ма-
лай”,1989;  “Күктә ничә йолдыз бар?”, 1991; ”Яралы күк”,1994; “Күз-
гә күз”, 1996;  “Атларым-колынна-
рым”, 1997; “Чәчәк”,1999; “Чакма-
таш”, 2000;  “Сайланма әсәрләр” 4 томда, 2001 - 2003:  I том. ”Ва-
сыять”, 2001;  II том .“Хәерле көн”, 2002; III том.  “Суга язылган хакый-
катьләр”, 2002; IV том. Повестьлар, киносценариилар, 2003; “Амбирак”, 2003; ”Абага чәчәге”, 2006 и һ.б.



# Биографиясеннән...




1946 нчы елның 14 нче декабрендә Азнакай районы Әсәй авылында Гариф абый һәм Бәдриямал апалар аиләсендә туа. Ул бала чагында күренекле рәссам яки философ булу турында хыяллана.

Әйе, бүген Нур Әхмәдиев күренекле, ләкин рәссам , философ び булар... 

# Тематиканы билгелә.



Бирем :

Шигырьне тыңларга һәм темасын билге-ләргә. Нәтиҗә ясар-га, мисал китерергә.

# Табигатькә сакчыл караш



**Нәтиҗә:**

Шагыйрь үзебезне бар ит-
кән, сыендырган,туендыр-
ган табигатьнең яклаучысы
булып гәүдәләнә. Әйләнә-
тирә мохитнең бөтенлеге
җирдән генә түгел, күкләр-
дән дә бәйле икәнлеген ис-
кәртә. Бу темага “Йокысыз-
лык”,“Яралы күк”, “Туган як”
циклына кергән шигырьлә-
рен күрсәтә алабыз.

# Туган якка мәхәббәт



**нәтиҗә :**

Туган якка мәхәббәт хисе белән сугарылган шигырьләр Н. Әхмәдиев иҗатында аеруча күп. “Туган җирдә”, “Әсәй турында җыр”, “Тымытыгым”, “Кичке авыл”, “Туган авылым” –шуларның берничәсе генә. Нур Әхмәдиев, Сәгыйть Рәмиев кебек, шәһәрдә авылын сагынып яшәүче авыл баласы .

Сау бул ,әткәй,

Сау бул, әнкәй җаным,

Хат алуга дога кылыгыз.

Тизрәк күрешүне өмет итеп,

Сәлам белән- сезнең улыгыз.

# Ата-анага, туганнарына, кадерле затларына мәхәббәт, хөрмәт



**Нәтиҗә:**

Ата-анага, туганнарына, авылдашларына мәхәббәт хөрмәт темасы. Мәхәббәт төшенчәсенә туган илгә, туган җиргә,кешеләргә, үз якыннарыңа - әти- әниеңә, туганнарыңа, кадерле затларыңа булган хисләрне дә кертергә кирәк.“ Фәрит энекәшкә”, Авылга хат”, “Апалар”, “Әткәйгә”, “Диалектика”, “Авылдашым”, “Авыл иртәсе” шигырьләрен шул темага кертер идем.

Әнкәңне дә апкитерләр, Халык дошманының Яңа туган баласы да Куркыныч бит аның.

# Репрессия еллары турында уйланулар




Илебез тарихында кайгы -хәсрәт, кан-яшьләр, гаепсезгә хөкем ителгәннәрнең төрмә диварларында, себер тайгаларында калган сәламәтлекләре, вакытсыз киселгән гомерләре, кимсенү, хурлык чоры булган шәхес культы еллары турында Н. Әхмәдиев ачынып яза. “1937 ел”, “Илдән сөрелгәннәр кайтавазы”, “Колыма шигыре”, “Кушуч арыш” поэмасы гаепсезгә хөкем ителгәннәрнең җан авазы булып яңгырый.


Кемдә дә бер йөрәк, Кемдә дә бер гомер. Ир-егет ил өчен Гомерен дә бирер.

# Батырлык, патриотизм



Татар халкында бөтен гомерен, хезмәтен халкына багышлаган, яуларда батырларча башларын салган геройлар бик күп. Н.Әхмәдиев олуг шәхесләребезне, батыр якташларыбызны шигырьләре аша киләчәк буыннарга да үрнәк итеп җиткерә. “Бакый Урманчега мәдхия”, “Каюм Насыйри”, “Тукайга”, “Йөрәк турында баллада”, “Пистолет һәм шагыйрь турында баллада” һ. б. шигырьләре батырлык темасына керә.

# Тормыш, яшәеш, үлем турында фәлсәфи уйланулар




“Пирамидаларга карыйм - сыеп
бетми хәтта уйларга,”- дип, әдип
“Җиде могҗизаның берсе”нә хәй-
ран калуын яшерә алмый.Биш мең
еллык чал тарих сеңгән сфинкс-
лар янында нинди генә фәлсәфи
уйлар тумаган. “Помпей колонна-
сы” исемле шигырьдә патшаларны
гына түгел, тиран булырга тырыш-
кан вак-төяк хакимнәрне, түрәләр-
не дә сискәндererлек фикерләр
әйтелә. “Газиз дошманыма”, “Ри-
цага күтәрелү”, “Пицунда хикәяте”-
шагыйрьнең тормыш, яшәеш, го-
мер, үлем турындагы фәлсәфи
уйланулары.

Туган җирне сайламыйсың, Татар булган атам-анам. Рус туган миңа, булган туган. Шуңа бәхетле торам.

# Туган телне саклау

Телне саклау- милләтне, нәселне, халыкны, илне саклау ул. Нур Әхмәдиев-Тукай, Исхакый-лар кебек, үз татарының милләтпәрвәр улы. ”Әлмәт татары”, ”Татар йөрәге”, “Татарым”, “Сандугачка аңа барыбер”, “Ирекле коллар”, “Татарыма” шигырьләре, “Чукындыру” поэмасы туган телне саклау, милләтең белән горурлану темасына язылган.



Пар былбыллар кавышсалар, Жыру тынмас. Яна белмәгән йөрәккә Былбыл кунмас.

# Мәхәббәт, сөю- мәңгелек хис



Мәхәббәт - мәңгелек хисләр дәрьясы, шагыйрьләрне һәрвакыт үзенә җәлеп итеп, дулкынландырып торучы бер халәт. Гасырлар буе агып та саекмас чишмә, сулмас гөл ул. Шагыйрь иҗатында бу темага шактый урын бирелгән. “Чакматаш” җыентыгында әдип бу темага караган шигырьләрен “Мәҗнуниана” дип исемли.



[illegible]



Өй эше:

“Сүзләр тезәм”, “Әле ярый кеше булганмын”, “Биек булмаса да тауларым бар”, “Үз мичемнең төтене” шигырьләрен укып, теманы билгеләргә. Дәрес презентациясен флешкага алып,нәтиҗәләрне әдәбият дәфтәренә язарга.

Булдырдыгыз!

